ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

22.06.2022 г. Казань № 74-24/кс-2022

2022 елга «ТаграС-ЭнергоСервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасындагы кайнар суга тарифлар билгеләү турында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендәге тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2022 елның 22 июнендәге 15-ПР номерлы Идарә утырышы беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Кайнар су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «ТаграС-ЭнергоСервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (алга таба – «ТаграС-ЭнергоСервис» ҖЧҖ) тарафыннан җибәрелә торган кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасындагы кайнар суга әлеге карар кушымтасы нигезендә тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2022 елның 1 августыннан 2022 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Кайнар су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «ТаграС-ЭнергоСервис» ҖЧҖ Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 номерлы карары белән расланган Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартларына туры китереп, ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турындагы карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көннән соңга калмыйча ачарга.

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 22.06.2022 № 74-24/кс-2022 карарына кушымта

# Кайнар су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «ТаграС-ЭнергоСервис» ҖЧҖ тарафыннан кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасындагы кайнар суга 2022 елга тарифлар

| т/с | Кайнар су белән тәэмин итүче оешма, муниципаль берәмлек исеме | Кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасындагы кайнар суга тариф (ике компонентлы) | |
|---|---|---|---|
| | | Салкын суга компонент, сум/куб.м | Җылылык энергиясенә компонент, сум/Гкал |
| | | 01.08.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 01.08.2022 башлап 31.12.2022 кадәр |
| 1 | «ТаграС-ЭнергоСервис» ҖЧҖ* | | |
| 1.1 | Азнакай муниципаль районы кулланучылары | | |
| 1.1.1 | Бүтән кулланучылар (тарифлар өстәмә хак салымыннан башка күрсәтелгән) | 30,38 | - |
| 1.2 | Әлмәт муниципаль районы кулланучылары | | |
| 1.2.1 | Бүтән кулланучылар (тарифлар өстәмә хак салымыннан башка күрсәтелгән) | 36,62 | - |
| 1.3 | Лениногорск муниципаль районы кулланучылары | | |
| 1.3.1 | Бүтән кулланучылар (тарифлар өстәмә хак салымыннан башка күрсәтелгән) | 28,77 | - |

<*> Җылылык энергиясенә компонент яклар килешүе буенча Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары белән расланган Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя кую нигезләренең 5(5) пункты нигезендә билгеләнә.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге